ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.01.2022 п.г.т. Алексеевское № 1

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 2018 елның 24 апрелендәге 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 07 декабрендәге 1189 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын исәпкә алып

**карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 2018 елның 24 апрелендәге 40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта:

1 пунктчада «50» санын «8» санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчада:

икенче абзацта «25» санын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» санын «2» санына алмаштырырга;

6 пунктчада:

өченче абзацта «35» санын «7» санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» санын «10» санына алмаштырырга;

8 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «тугыз айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер бөтен уннан сигез айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «өч айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе О.Н. Леденцовка йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы** **С.А. Демидов**